ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 март, 2023 ел № 22/10

Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 13 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге ШәҺәр Советы Регламентына (Шәһәр Советының 2014 елның 21 февралендәге 29/18, 2014 елның 10 июлендәге 31/22, 2019 елның 7 октябрендәге 33/16, 2020 елның 28 маендагы 39/4 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 29 статьяның 2 өлешендә «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларга әзерлек һәм үткәрүне оештыра торган сайлау комиссиясе рәисе» сүзләренә алыштырырга;

2) 79 статьяның 1 өлешендә:

- 7 пунктта «шәһәр сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү,» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 13 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3) 16 бүлекне көчен югалткан дип танырга.

2. Шәһәр Советының 2007 елның 17 маендагы 22/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә гражданнарны сораштыру турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2021 елның 27 маендагы 7/9 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 17-26 пункларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Сораштыру үткәрү буенча функцияләр сораштыру үткәрү буенча комиссиягә (алга таба - Комиссия) йөкләнә. Комиссия составына Шәһәр Советы Карары белән 7-10 кеше раслана.

Комиссия составына мәҗбүри рәвештә Шәһәр Советы, Башкарма комитет вәкилләре, шулай ук сораштыру уздырыла торган территория җәмәгатьчелеге вәкилләре кертелә.

18. Комиссия вәкаләтләре:

1) гражданнарны сораштыру үткәргәндә әлеге Нигезләмәне үтәүне оештыру;

2) сораштыру үткәрү пунктларын җиһазлау;

3)Шәһәр Советы тарафыннан расланган форма буенча сораштыру исемлекләре һәм сораштыру кәгазьләре әзерләүне тәэмин итү;

4) сораштыру вакытында имзалар җыюны оештыру;

5) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртип буенча, сораштыру вакытында халыкның тавыш бирүен оештыру;

6) җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

7) гражданнарны сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү;

8) гражданнарны сораштыруга бәйле гаризаларны һәм шикаятьләрне карау;

9) гамәлдәге законнарга һәм әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

19. Комиссия Шәһәр Советының аны оештыру турында карары кабул ителгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча чакырыла.

20. Беренче утырышта Комиссия ачык тавыш бирү юлы белән үз составыннан Комиссия рәисен, урынбасарын (урынбасарларын) һәм секретарен сайлый, сораштыру участокларын раслый, шулай ук, әгәр сораштыру үткәрү пунктларда үткәрелсә, мондый пунктларның санын һәм урнашу урынын раслый.

21. Комиссия утырышларын, зарурлыктан чыгып, аның Рәисе чакыра.

22. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының билгеләнгән санының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

23. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш нигезендә кабул ителә.

24. Комиссия гражданнарны сораштыру үткәрү өчен кирәкле эшче төркемнәр булдырырга хокуклы.

25. Комиссия эшчәнлеген оештыруны һәм матди-техник тәэмин итүне Башкарма комитет башкара.

26. Шәһәр Советы тарафыннан сораштыру нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң Комиссия вәкаләтләре туктатыла.»

2) 32 пунктта «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

3) 33 пунктның икенче абзацында «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

4) 35 пунктта «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

5) 36 пунктта «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

6) 37 пунктта «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

7) 40 пунктта:

- беренче абзацта «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

- 10 пунктчада «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

8) 43 пунктның 2 пунктчасында «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

9) 44 пунктта «участок комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

10) 45, 46, 47 пунктларны көчен югалткан дип танырга;

11) 48 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«48. Комиссия беркетмәсенә түбәндәге карарларның берсе кертелә:

1) сораштыруны узган дип тану;

2) сораштыруны узмаган дип тану;

3) сораштыруны гамәлгә яраксыз дип тану.»;

12) 49 пунктта «Район комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

13) 50 пунктта «Район комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

14) 51 пунктта «Район комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

15) 53, 55, 56, 57, 58 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

16) 59 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««59. Сораштыру йомгаклары турындагы беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм Комиссиянең шунда булган барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәнең беренче нөсхәсе сораштыру нәтиҗәләре бергә Шәһәр Советына җибәрелә. Сораштыру йомгаклары турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсенә Комиссия әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук гражданнардан язма рәвештә кергән шикаятьләр һәм гаризалар, алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә. Сораштыру йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе комиссия әгъзаларының таныкланган аерым фикерләре күчермәләре, гражданнарның шикаятьләре, гаризалары, шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар белән бергә Башкарма комитетта саклауда кала.»;

17) 60 пунктта «Сайлау комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

18) 61 пунктта «Сайлау комиссиясе» сүзләрен «Комиссия» сүзенә алыштырырга;

3. Шәһәр Советының 2007 елның 17 маендагы 22/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә гражданнарның хокук иҗат инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2021 елның 27 маендагы 7/9 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 бүлекне көчен югалткан дип танырга;

2) 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Инициатив төркем төзү турындагы карар хокук иҗат инициативасын хуплап имзалар җыю өчен нигез булып тора. Имза кәгазьләре инициатив төркем хисабына әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралган тәртиптә әзерләнә.»;

3) 23 пунктта «теркәү» сүзен «төзү» сүзенә алыштырырга;

4) 24 пунктта «Сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарәнең тиешле органы» сүзләренә алыштырырга;

5) 26 пунктта «Сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органы» сүзләренә алыштырырга;

6) 28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органы» сүзләренә алыштырырга;

- «теркәү» сүзен «карау» сүзенә алыштырырга;

7) 7 бүлек исемен түбәндәге редакциядә язарга «Хокук иҗат инициативасын рәсмиләштерү һәм карау»;

8) 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарәнең тиешле органы» сүзләренә алыштырырга;

- «теркәү» сүзен «карау» сүзенә алыштырырга;

9) 30 пунктны көчен югалткан дип танырга;

10) 31 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31. Хокук иҗат инициативасын рәсми кертү датасы булып, җирле үзидарәнең тиешле органына хокук иҗат инициативасын теркәү турында карар, хокук иҗат инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелә торган муниципаль хокукый акт проекты тексты, аңа кушымта итеп бирелгән документлар, шулай ук хокук иҗат инициативасы турында беркетмә керү датасы санала.»;

«11) 32 пунктның 3 пунктчасын көчен югалткан дип танырга;

12) кушмтада «,сайлау комиссиясе тарафыннан теркәлгән (сайлау комиссиясе карары №____ _____ ел,)» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 Карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турында Нигезләмәнең (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/20, 2010 елның 26 маендагы 50/6 номерлы Карарлары редакциясендә) 3.9 пунктында «, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев